**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 14 апрелендәге 1257 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның**
**10 гыйнварындагы 2 номерлы карары белән расланган**
**Ферма-2 территориясен планлаштыру проектына**
**үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьяларына таянып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 10 гыйнварындагы 2 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 22 сентябрендәге 2825 номерлы һәм 2024 елның 31 гыйнварындагы 348 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Ферма-2 территориясен планлаштыру проектына, әлеге карарның кушымтасы нигезендә аның аерым өлешләрен раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 14 апрелендәге
1257 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 10 гыйнварындагы 2 номерлы карары белән расланган Ферма-2 территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Кызыл линияләр, планлаштыру структурасы элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары күрсәтелгән территорияне планлаштыру проекты сызымын әлеге үзгәрешләрнең 1 номерлы кушымтасы нигезендәге редакциядә бирергә.

2. III «Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмә» бүлегендә:

2.1. 1.2 пунктта:

2.1.1. унбишенче абзацка түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә: «Проект белән регби үзәге төзү күздә тотыла»;

2.1.2. унҗиденче абзацта түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә: «Спорт билгеләнешендәге объектларны план буенча урнаштыру зонасында регби үзәге җир кишәрлегенең алгы, ян һәм арткы чикләреннән минималь ераклык, гамәлдәге законнар, техник нормалар, регламентлар һәм кагыйдәләр, башка норматив хокукый актлар үтәлгән очракта, нульгә тигез итеп билгеләнә»;

2.1.3. 1 «Планлаштыру проекты территориясенең техник-икътисади күрсәткечләре» таблицасында:

2.1.3.1. сигезенче юлдагы «16,00» саннарын «7,88» саннарына алмаштырырга, «21,65» саннарын «10,67» саннарына алмаштырырга;

2.1.3.2. тугызынчы юлдагы «7,57» саннарын «1,36» саннарына алмаштырырга, «10,3» саннарын «1,86» саннарына алмаштырырга;

2.1.3.3. түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| Атамасы | Мәйданы, га | Баланс, % |
|---|---|---|
| «Спорт билгеләнешендәге объектларны урнаштыру зонасы | 6,21 | 8,42 |

| | | |
|---|---|---|
| Белем бирү оешмаларын урнаштыру зонасы | 4,58 | 6,22 |
| Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны план буенча урнаштыру зонасы | 3,53 | 4,8» |

2.1.4. 3 «Иҗтимагый билгеләнештәге объектлар характеристикалары» таблицасында бишенче юлдан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| **Атамасы** | **Егәрлеге** |
|---|---|
| «Регби үзәге* | 1 объект» |

2.2. 1.5.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Регби үзәге өчен хуҗалык-эчү ихтыяҗларына исәпләнгән су куллану күләме тәүлегенә 37,18 куб. м тәшкил итә. Су белән тәэмин итү челтәренә тоташтыру ноктасы – Рауис Гәрәев урамындагы 62 йорт янындагы Ø 315 мм лы сүүткәргечкә»;

2.3. 1.5.2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Регби үзәге өчен су чыгару буенча исәпләнгән күләм тәүлегенә 25,10 куб.м тәшкил итә. Су чыгару челтәрләренә тоташтыру ноктасы – “Фермаполис” торак комплексы янында урнашкан Ø 225 мм канализация коллекторына»;

2.4. 1.5.3 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Регби үзәге территориясеннән яңгыр суларын агызу күләме – тәүлегенә 267 л. Проект карарлары белән ябык типтагы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү, аны “Тулпар” универсаль спорт комплексы тирәсендә яңгыр канализациясе челтәрләренә тоташтыру каралган»;

2.5. 1.5.4 пунктчасында:

2.5.1. уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Проектта гамәлдәге трансформатор подстанциясен юл төзелеше зонасыннан чыгару каралган. Трансформатор подстанциясе чыгарылганчы, регби үзәген электр белән тәэмин итү реконструкцияләнергә тиешле гамәлдәге трансформатор подстанциясеннән аның егәрлеген арттырып башкарыла»;

2.5.2. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Регби үзәген электр энергиясе белән тәэмин итү үзәге булып «Центральная» подстанциясе тора. Тоташтыру планлаштырыла торган егәрлек – 925,5 кВт»;

2.6. 1.5.5 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Регби үзәге өчен җылылык йөкләнеше 1,43415 Гкал/сәг тәшкил итә. Җылылык чыганагы – участок территориясендәге котельный»;

2.7. 1.5.7 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Регби үзәге өчен регби үзәге территориясендә котельный төзү каралган. Планлаштырыла торган газ куллану күләме – 208,5 куб. м/сәг. Котельныйны газ белән тәэмин итү регби үзәге участогыннан 1, 2 номерлы урамнарның кызыл линияләренә чыгарыла торган DN 325 уртача басымлы газүткәргечтән планлаштырыла».

3. IV «Территориянең планлаштырыла торган үсеше чираты турында нигезләмә» бүлегенә, беренче чиратка кагылышлы өлешенә:

3.1. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:


«- регби үзәген төзү»;

3.2. түбәндәге эчтәлекле искәрмә өстәргә:

«Искәрмә. Регби үзәген төзүгә рөхсәт алганчы, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә регби үзәге участогы өчен О5 территориаль зонасын – спорт объектлары урнаштыру зонасын билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү зарур».

---

Приложение к изменениям, вносимым в проект планировки территории Фермы-2, утвержденный Постановлением Исполнительного комитета г.Казани от 10.01.2022 №2




Фрагмент чертежа планировки территории с указанием красных линий, границ элементов планировочной структуры, зон планируемого размещения объектов капитального строительства.

## УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

- Граница внесения изменений
- красная линия — Действующая красная линия улично-дорожной сети
- кл топ — Действующая красная линия территории общего пользования
- Существующая сохраняемая застройка
- Граница зоны размещения объектов капитального строительства
- Граница зоны планируемого размещения объектов капитального строительства
- 5 — Зона планируемого размещения объектов общественно-делового назначения
- 9 — Зона размещения объектов спортивного назначения
- 6 — Зона размещения образовательных организаций
- 1 — Порядковый номер зоны размещения
- 6 — Вид зоны размещения объектов капитального строительства
- 4,61 — Площадь зоны размещения (га)
- 5.1.1* — Коды видов разрешенного использования
- 0 — Максимальная общая площадь жилищного фонда (тыс.кв.м)
- н.у — Максимальная этажность
- Трансформаторная подстанция, реконструкция**
- Трансформаторная подстанция, проект**
- Котельная, проект**
- ЦТП — Центральный тепловой пункт, проект**

*Код вида разрешенного использования, подлежащего установлению только после внесения изменений в Правила землепользования и застройки г. Казани

**Расположение объекта в пределах зон является ориентировочным, устанавливается на дальнейшей стадии проектирования

